Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге
Байлар авылындагы

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2019 елның 23 ноябре № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Байлар авылында гражданнар җыены **КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. 2020 елда, көндезге формада укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, Ютазы муниципаль районының Байлар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Байлар авылында юлларны кардан чистарту;

Байлар авылында агачларны кисү, зират ихатасын алыштыру (сатып алу, килешү буенча эшләргә түләү) ;

- Байлар авылы Тукай урамында тузган асфальт катламын (асфальтка асфальт) тергезү.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга һәм карар Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда да урын алырга тиеш.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Урыссу авыл җирлеге Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Ф. Г. Әминова

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРЫССУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ * СОВЕТ УРУССИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * Для документов